ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2024 ел Ульянково ав. № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Ульянково авыл
җирлегенең Ульянково авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 24 ноябренә 18 сәгать 30 минутка Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 нчы йорт адресы буенча урнашкан Ульянково мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын беренче этабын билгеләргә.
2. 2024 елның 25 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Ульянково авылы, Мәктәп урамы, 39 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның бишенче этабын билгеләргә.
3. 2025 елның 26 ноябренә 11 сәгать 30 минутка Ульянково авылы, Яшел урамы, 25 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның өченче этабын билгеләргә.
4. 2024 елның 26 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Ульянково авылы, 34а йорт адресы буенча урнашкан Ульянково төп гомуми белем бирү мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның дүртенче этабын билгеләргә.
5. 2024 елның 27 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Ульянково авылы, Зур урамы, 18 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Ульянково торак пунктында

үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның алтынчы этабын билгеләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегене Ульянково авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (шул исәптән янгын сүндерү автомашинасын, җиһазларын, бинасын һәм ДЕПО хезмәткәрен карап тоту);

- Су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; - Торак пункт территориясен төзекләндерү (шул исәптән ял паркы территориясен чүпләү)"»

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Ульянково авыл җирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**